**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.03.2020 № 176

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту чараларын гамәлгә ашыру буенча оператив штаб төзү турында

Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту, аның барлыкка килүенә юл куймау буенча оператив чаралар эшләү максатларында, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту чараларын гамәлгә ашыру буенча, 1нче кушымтада күрсәтелгән составта оператив штаб төзергә.

2. 2нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясе таралуны профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту чараларын гамәлгә ашыру буенча оператив штаб турында Нигезләмәне расларга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тоту өчен җаваплылыкны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 мартындагы 176 номерлы карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту чараларын гамәлгә ашыру буенча оператив штаб составы

<u>Оператив штаб җитәкчесе</u>:

| | | |
|---|---|---|
| Маняпов Линар Нурислам улы | - | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

<u>Оператив штаб җитәкчесе урынбасары</u>:

| | | |
|---|---|---|
| Газизуллин Роберт Адлер улы | - | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |

<u>Оператив штаб әгъзалары</u>:

| | | |
|---|---|---|
| Шәмсетдинов Руслан Ринат улы | - | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |
| Габдрахманов Рөстәм Рәшит улы | - | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Нәфыйгина Ләйсән Мидхәт кызы | - | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Белов Михаил Иван улы | - | Нурлат муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хәмзин Рәфис Рафик улы | - | Нурлат шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сәгъдиев Айдар Рөстәм улы | - | «Нурлат РҮХ» ДАССОның баш табибы (килешү буенча) |
| Хәйруллина Флюра Сәлим кызы | - | ТР буенча Роспотребнадзор Идарәсенең Нурлат, Аксубай районнарында территориаль бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Гаврилов Леонид Валерий улы | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Попов | - | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ |

| | | |
|---|---|---|
| Евгений Анатолий улы | | Баш идарәсенең 11 ПСО ПСО ФПС 125 ПСЧ башлыгы-Нурлат муниципаль районында КЧС һәм ОПБ рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Иванов Александр Александр улы | - | «Нурлатнефть» НГДУсы баш инженеры (килешү буенча) |
| Закиров Илдар Илсөяр улы | - | «Татспецтранспорт ИК» АҖнең Нурлат УТТсы (килешү буенча) башлыгы |
| Шарапов Рамил Шакир улы | - | «Промочистка» ҖЧҖ идарәчесе (килешү буенча) |
| Нутфуллин Ранас Нуруллович | - | директор МУП «УК ЖКХ» (по согласованию) |
| Терентьева Оксана Геннадий кызы | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Нурлат муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 мартындагы 176 номерлы карарына 2 нче кушымта

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Нурлат муниципаль районында (алга таба - Штаб) коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту чараларын гамәлгә ашыру буенча оператив штаб Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы коллегиаль киңәшмә һәм консультатив орган булып тора.
1.2. Штаб үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Штабның максатлары һәм бурычлары

2.1. Штаб Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары, учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлеген координацияләү максатыннан оештырылган.
2.2. Түбәндәгеләр Штабның бурычлары булып тора:
2.2.1. Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясе белән авыручылар санының торышы турындагы мәсьәләләрне карау.
2.2.2. Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту эшчәнлеген тормышка ашырганда җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.
2.2.3. Нурлат муниципаль районының сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек алып баручы дәүләт хакимияте органнарыннан һәм оешмаларыннан Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясен профилактикалау һәм таралуын контрольдә тоту эше турында кергән мәгълүматны карау.
2.2.4. Нурлат муниципаль районында коронавирус инфекциясе белән авыручыларны булдырмауга юнәлдерелгән чараларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

## 3. Штаб вәкаләтләре

Штаб:
3.1. Штаб алдына куелган бурычларны хәл итү өчен дәүләт органнарыннан, РФ һәм ТР башкарма органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик һәм физик затлардан кирәкле мәгълүмат һәм материалларны тиешле тәртиптә соратып ала.
3.2. Сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек алып баручы җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләрен, Нурлат муниципаль районының башка органнары вәкилләрен штаб утырышына чакыра.
3.3. Үз компетенциясе кысаларында тәкъдим итү характерындагы карарлар кабул итә.
3.4. Штаб компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләүне

гамәлгә ашыра һәм аларны Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнарына карауга кертә.
3.5. Штаб компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра һәм аларны Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнарына карауга кертә.
3.6. Үз эшенә экспертларны, белгечләрне һәм консультантларны җәлеп итә.
3.7. Штаб максатларына һәм бурычларына туры килә торган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## 4. Штаб эшчәнлеге тәртибе

4.1. Штаб әгъзалары яки аларның вәкаләтле вәкилләре үз эшчәнлекләрен Штаб утырышларында катнашу юлы белән штаб җитәкчесе раслаган план нигезендә башкаралар.

4.2. Штаб утырышлары:
4.2.1. Штаб утырышлары кирәк очракта Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре башлыгы яисә Штаб җитәкчесе карары белән үткәрелә.
4.2.2. Штаб утырышын штаб җитәкчесе яки ул булмаганда штаб җитәкчесе урынбасары штаб җитәкчесе кушуы буенча алып бара.
4.2.3. Штаб утырышы нәтиҗәләре штаб җитәкчесе кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.3. Штаб җитәкчесе:
4.3.1. Штаб утырышларын үткәрү турында карар кабул итә, мондый карар Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре башлыгы тарафыннан кабул ителгән очраклардан тыш, штаб утырышын үткәрү көнен, вакытын һәм урынын билгели.
4.3.2. Штаб эшен җитәкли һәм координацияли.
4.3.3. Штаб утырышларын алып бара һәм штаб утырышлары беркетмәләренә кул куя.
4.3.4. Штаб утырышына экспертлар, белгечләр һәм консультантлар чакыру турында карар кабул итә.
4.3.5. Штаб белән җитәкчелек итү буенча башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

4.4 Штаб әгъзалары:
4.5.1. Штаб утырышы көн тәртибенә сораулар кертү өчен тәкъдимнәр кертәләр.
4.5.2. Штаб утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашалар.
4.5.3. Штаб утырышларында бәян ителгән мәсьәләләргә кагылышлы искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм өстәмәләне язмача яки телдән әйтәләр.